РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

№ 42

27 сентябрь, 2018 ел

**Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре җирле үзидарә органы карамагындагы оешма (учреждение) җитәкчесе тарафыннан, вазыйфаи бурычларны үтәгәндә, мәнфәгатьләр каршылыгына китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе турында**

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Түбән Кама шәһәр Советы

**КАРАР БИРӘ**:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре җирле үзидарә органы карамагындагы оешма (учреждение) җитәкчесе тарафыннан, вазыйфаи бурычларны үтәгәндә, мәнфәгатьләр каршылыгына китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибен (Кушымта) расларга.
2. Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре җирле үзидарә органнарына:

2.1. ведомство карамагындагы оешмалар (учреждениеләр) җитәкчеләрен әлеге карар белән таныштырырга;

2.2. җирле үзидарә органнары карамагындагы оешмалар (учреждениеләр) уставларына, шулай ук аларның җитәкчеләре белән төзелгән хезмәт килешүләренә ведомство карамагындагы оешма җитәкчесенең, хезмәт вазыйфаларын башкарганда, мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында җирле үзидарә органы җитәкчесенә хәбәр итәргә тиешлекне билгеләүче үзгәрешләр кертергә

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында һәм Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама шәһәр Советы регламенты, җирле үзидарә һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры А.Р. Метшин

Кушымта
Түбән Кама шәһәр Советының
42нче номерлы карарына
27 сентябрь, 2018 ел

**Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре җирле үзидарә органы карамагындагы оешма (учреждение) җитәкчесе тарафыннан, вазыйфаи бурычларны үтәгәндә, мәнфәгатьләр каршылыгына китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре җирле үзидарә органы карамагындагы оешма (учреждение) җитәкчесе тарафыннан, вазыйфаи бурычларны үтәгәндә, мәнфәгатьләр каршылыгына китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итү процедурасын регламентлаштыра (алга таба – Тәртип)

2. Әлеге Тәртиптә мәнфәгатьләр каршылыгы астында вазыйфа биләп торган затның шәхси кызыксынуы (турыдан-туры яисә турыдан-туры булмаган), аны биләү мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм җайга салу буенча чаралар күрү бурычын күздә тота, аларның вазыйфаи (хезмәт) бурычларын (вәкаләтләрне гамәлгә ашыру) тиешле, объектив һәм гадел үтәүгә йогынты ясый яисә йогынты ясый алырга мөмкин булган хәл аңлатыла.

3.Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре җирле үзидарә органы карамагындагы оешма (учреждение) җитәкчесе коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнары һәм оешма (учреждение) уставы нигезендә мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килүе турында хәбәр итәргә, шулай ук мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау яки җайга салу буенча чаралар күрергә тиеш.

4.Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре җирле үзидарә органы карамагындагы оешма (учреждение) җитәкчесе эш бирүчегә (эшкә алучы вәкиленә) хезмәт вазыйфаларын башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китерүче яисә китерәчәк шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында бу хакта билгеле булган көннән соң килүче бер эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр итәргә тиеш.

5.Хезмәт вазыйфаларын башкарганда, әлеге Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән вакытка, ведомство карамагындагы оешма (учреждение) җитәкчесенә бәйле булмаган сәбәпләр аркасында, мәнфәгатьләр каршылыгына китерүче яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итү мөмкин булмаганда, хәбәрнамә аны бетергәннән соң бер эш көненнән дә соңга калмыйча тапшырыла.

6.Хәбәр, вазыйфаи бурычларны үтәгәндә, мәнфәгатьләр каршылыгына китерүче яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәрнамә рәвешендә язма формада рәсмиләштерелә (алга таба - хәбәрнамә).

Хәбәрнамәдә түбәндәге мәгълүматлар күрсәтелә:

а) уведомление тутыручы ведомство карамагындагы оешма җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме, аның вазыйфасы;

б) ведомство карамагындагы оешма җитәкчесенең шәхси кызыксынуы (турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган) хезмәт бурычларын тиешенчә, объектив һәм гадел үтәүгә йогынты ясый яки йогынты ясый алырга мөмкин булган хәлнең тасвирламасы;

в) ведомство карамагындагы оешма җитәкчесе тарафыннан хезмәт бурычларын тиешенчә үтәүгә йогынты ясый яки йогынты ясый ала торган шәхси

кызыксынучанлыкның квалификацияле билгеләре (ведомство карамагындагы оешма җитәкчесе һәм (яки) аның белән якын туганлыкта яки үги туганлыкта торучы затлар (ата-аналар, ир яки хатын, балалар, абыйлар, апалар, шулай ук ир яки хатынның абыйлары, апалары, ата-аналары, балалары һәм баларның ир яки хатыны) тарафыннан, ведомство карамагындагы оешма җитәкчесе һәм (яки) аның белән якын туганлыкта яки үги туганлыкта торучы затлар белән милек, корпоратив яки башка якын мөнәсәбәтләр белән бәйле гражданнар яки оешмалар тарафыннан акчалата, башка мөлкәт, шул исәптән мөлкәт хокуклары, мөлкәти характердагы хезмәт күрсәтүләр рәвешендә керемнәр алу, башкарылган эшләр яки нинди дә булса файда (өстенлекләр) алу мөмкинлекләре);

г) аларны үтәүгә шәхси кызыксыну тискәре йогынты ясарга мөмкин яки тискәре йогынты ясый торган хезмәт вазыйфалары тасвирламасы;

д) мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килү мөмкинлеген булдырмас яисә килеп туган мәнфәгатьләр каршылыгын җайга сала алырлык тәкъдим ителгән чаралар;

е) хәбәрнамә тутыру датасы;

ж) хәбәрнамә тутыручы затның имзасы.

7. Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре җирле үзидарә органы карамагындагы оешма (учреждение) җитәкчесе эш бирүчегә (эшкә яллаучы вәкиленә) 1 нче кушымта нигезендә төзелгән хәбәрнамә җибәрә.

8. Эш бирүче (эшкә яллаучы вәкиле) адресына килгән хәбәрнамәләр карау өчен хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм коррупцияне профилактикалау һәм булдырмау буенча алга таба чаралар эшләү өчен мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Комиссиягә (алга таба - Комиссия) тапшырыла.

9. Хәбәрнамәләрне теркәү Комиссия секретаре тарафыннан, үрнәге әлеге Тәртип буенча 2 нче кушымта белән каралган, хәбәрнамәләрне теркәү журналында башкарыла.

Комиссия секретаре хәбәрнамәдә күрсәтелгән мәгълүматның конфиденциальлеген үтәргә тиеш. Конфиденциаль мәгълүматны таратуда гаепле зат, Россия Федерациясе законнары нигезендә, дисциплинар, башка җаваплылыкка тартыла.

10. Теркәү турында тамга белән хәбәрнамә күчермәсе, хәбәрнамәләрне теркәү журналында имзаланып, Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре җирле үзидарә органы карамагындагы оешма җитәкчесенә кулга бирелә, яисә почта аша алу турында хәбәрнамә белән җибәрелә.

11. Хәбәрнамәләрне алдан карау барышында, Комиссия билгеләнгән тәртиптә хәбәрнамәләрне җибәргән затлардан, аларда бәян ителгән хәлләр буенча аңлатмалар алырга һәм билгеләнгән тәртиптә дәүләт хакимиятенең федераль органнарына, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынган оешмаларга сорату җибәрергә хокуклы.

12. Хәбәрнамәләрне алдан карау нәтиҗәләре буенча, аларның һәркайсына дәлилле нәтиҗә әзерләнә.

Хәбәрнамәләрне алдан карау барышында алынган хәбәрнамәләр, нәтиҗәләр һәм башка материаллар, хәбәрнамәләр кергән көннән алып, җиде эш көне эчендә, комиссия утырышына тәкъдим ителә.

Әлеге Тәртипнең 11 пунктында күрсәтелгән сорату җибәрелгән очракта, хәбәрнамәләр, нәтиҗәләр һәм башка материаллар эш бирүчегә (эшкә алучы вәкиленә) хәбәрнамә килгән көннән 45 көн эчендә Комиссиягә тәкъдим ителә. Күрсәтелгән срок озайтылырга мөмкин, әмма 30 көннән дә артык түгел.

13. Комиссия хәбәрнамәләрне карый һәм алар буенча Комиссия турында Нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә карарлар кабул итә һәм эш бирүчегә (эшкә алучы вәкиленә) кабул ителгән карарны җибәрә.

14. Эш бирүче (эшкә алучы вәкиле) хәбәрнамәләрне Комиссия карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) хәбәрнамә җибәргән зат вазыйфаи бурычларын үтәгәндә, мәнфәгатьләр каршылыгы юк дип таныпга;

б) хәбәрнамә җибәргән зат вазыйфаи бурычларын үтәгәндә, шәхси кызыксыну мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерә ала дип таныпга;

в) хәбәрнамә җибәргән зат тарафыннан мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килү мөмкинлеген булдырмаслык һәм (яисә) җайга сала алырлык чаралар үтәлмәгән дип таныпга.

15. Әлеге Тәртипнең 14 пунктындагы "б" пунктчасында каралган карар кабул ителгән очракта, Россия Федерациясе законнары нигезендә Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре җирле үзидарә органы карамагындагы оешма (учреждение) җитәкчесе мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу буенча чаралар күрә яисә чаралар күрүне тәэмин итә.

16. Әлеге Тәртипнең 14 пунктындагы «в» пунктчасында каралган карар кабул ителгән очракта, Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре җирле үзидарә органы карамагындагы оешма (учреждение) җитәкчесенә Россия Федерациясе Хезмәт кодексы, ведомство карамагындагы җирле үзидарә органы оешмасы (учреждениесе) уставында һәм хезмәт килешүендә каралган дисциплинар җәза бирелә.

Хәбәрнамә һәм хәбәрнамәне карап тикшерү белән бәйле башка материаллар Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре җирле үзидарә органы карамагындагы оешма (учреждение) җитәкчесенең шәхси эшенә теркәлә.

Түбән Кама шәһәре Мэры урынбасары Э.Р. Долотказина

Кушымта №1
Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре җирле үзидарә органы карамагындагы оешма (учреждение) җитәкчесе тарафыннан, вазыйфаи бурычларны үтәгәндә, мәнфәгатьләр каршылыгына китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибенә

___________________________________
(Түбән Кама шәһәр Советы рәисе, Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесенә)
__________________________________
(Ф.И.О.)
______________________ннан (ннән)
(Ф.И.О., вазыйфасы)

**ХӘБӘРНАМӘ**
**вазыйфаи бурычларны үтәгәндә, мәнфәгатьләр каршылыгына китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында**

Вазыйфаи бурычларны үтәгәндә, мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерә ала (кирәклесен ассызыкларга кирәк) торган минем шәхси кызыксынуларым барлыкка килү турында хәбәр итәм.

Шәхси кызыксыну барлыкка килүгә нигез булып торган шартлар:
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________

Аларны үтәүгә шәхси кызыксыну йогынты ясый яки йогынты ясарга мөмкин булган вазыйфаи бурычлар:
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________

Мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау яки җайга салу буенча тәкъдим ителгән чаралар_____________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________

Коррупцияне профилактикалау һәм булдырмау буенча алга таба чаралар эшләү (тиешлесен ассызыкларга кирәк) өчен хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Комиссия утырышында, әлеге белдерүне караганда, шәхсән катнашырга җыенам (җыенмыйм).

"__" ________ 20__ел ______________________________ ________________________

(хәбәрнамә җибәрүче затның имзасы) (имзаны расшифровкалау)

Кушымта №2
Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре җирле үзидарә органы карамагындагы оешма (учреждение) җитәкчесе тарафыннан, вазыйфаи бурычларны үтәгәндә, мәнфәгатьләр каршылыгына китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибенә

*Тәкъдим ителә торган үрнәк*

**Журнал**
**Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре җирле үзидарә органы карамагындагы оешма җитәкчесе (эшкә алучы вәкиле) тарафыннан вазыйфаи бурычларны үтәгәндә шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында эш бирүче (эшкә алучы вәкиле) гаризаларын теркәү**

| т/с № | Хәбәрнамәнең теркәү номеры | Хәбәр-намәне теркәү датасы | Хәбәрнамә тәкъдим ителгән | | Хәбәрнамә теркәлгән | | | Хәбәрнамәнең күчермәләрен алу турында билге (күчермәсен алган, имза) яки почта аша хәбәрнамә күчермәләрен җибәрү турында билге |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Ф.И.О. | вазыйфа | Ф.И.О. | вазыйфа | имза | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| | | | | | | | | |